Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин А.В. Туганов шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлешенең, 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлеше, 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең, 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләренең, шулай ук тулаем күрсәтелгән карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2021 елның 7 октябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең

4 статьясындагы 2 өлешенең, 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлеше, 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләренең, 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләренең, шулай ук тулаем күрсәтелгән карарның конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Туганов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья М.М. Хәйруллин мәгълүматын, яклар — гражданин А.В. Туганов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы Э.Ә. Нургалиева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 4 статьясындагы 2 өлеше белән, 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлеше, 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләре, 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләре, шулай ук тулаем күрсәтелгән карар белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлеше гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы (алга таба шулай ук — Район) территориясендә даими яшәүче 18 яшькә җиткән һәм 100 кешедән дә ким булмаган гражданнар төркеменнән чыгып эш итә ала дип билгели.

Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацындагы һәм 13 статьясындагы 4 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре буенча гавами тыңлаулар үткәрү срогы гавами тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт басылып чыккан көннән алып Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба шулай ук — Устав) проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча кимендә 30 көн тәшкил итә; Устав проекты яисә Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы (алга таба шулай ук — Район Советы) карары проекты буенча гавами тыңлаулар Район Советы тарафыннан билгеләнә һәм Устав тарафыннан билгеләнгән срокларда, ләкин күрсәтелгән проектлар басылып чыкканнан соң 15 көннән иртәрәк булмаган вакытта уздырыла.

Нигезләмәнең 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацлары гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар биргән гавами тыңлауларда катнашучы затлар, үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен, чыгыш ясарга хокуклы булып тора; чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гариза биргәндә катнашучы паспортын яисә паспортын алыштыручы документын, шулай ук юридик затлар өчен юридик затның исеме һәм адресы турында мәгълүматны һәм юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документны тапшыруын күз алдында тота.

Нигезләмәнең 9 статьясындагы 5 өлеше нигезендә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә мәҗбүри йомгаклау документы булып тора, аның формасы Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында китерелгән, ул чара уздырганнан

соң киләсе эш көненнән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көнлек срокта төзелә; гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш: каралуга чыгарылган мәсьәлә (сораулар); чараны үткәрү инициаторы; гавами тыңлауларны билгеләп кую турында муниципаль хокукый актның датасы, номеры һәм атамасы, шулай ук аны рәсми бастырып чыгару датасы; утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны; гавами тыңлауларда катнашучылар турында мәгълүмат; тикшерүгә чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (сорауларны) хәл итү буенча тәкъдимнәрнең һәм рекомендацияләрнең йомгаклау варианты; катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре.

Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы белән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә формасы билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында яшәүче, «Загородная» территориаль иҗтимагый үзидарәсен җитәкли. Районда үткәрелә торган гавами тыңлауларда даими катнашучы буларак, аларны үткәрүне регламентлаучы карала торган Нигезләмә аның конституциячел хокукларын боза дип саный.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлеше тиешле санда гражданнарны җыюны кыенлаштыра торган (инициатив төркем төзү өчен утырыш үткәрү, тиешле бина эзләү, беркетмәне, инициатив төркемнең барлык әгъзалары имзалары куелган имзалау кәгазен рәсмиләштерү) процедуралары катлаулы булганга күрә, 100 кешедән кимрәк булган гражданнар төркемнәренә гавами тыңлаулар үткәрү инициативасы белән мөрәҗәгать итү документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булмаганга күрә чикләү характерына ия.

Нигезләмәнең Устав проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү срогы гавами тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт басылып

чыккан көннән алып кимендә 30 көн булуын билгеләүче 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм Нигезләмәнең гавами тыңлаулар Устав белән билгеләнгән срокларда, әмма Устав проекты яисә Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты басылып чыкканнан соң 15 көннән дә соңга калмыйча билгеләнүен һәм уздырылуын күз алдында тоткан 13 статьясындагы 4 өлеше, мөрәҗәгать итүче раславынча, бер-берсенә каршы киләләр. Ул, хронологиядән чыгып, Устав проекты яисә Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты басылып чыккан вакыттан алып гавами тыңлаулар уздырган вакытка кадәр исәпләнгән срок гавами тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт басылып чыккан вакыттан алып аларны үткәргәнчегә кадәр исәпләнгән сроктан да ким була алмый дип саный.

Гражданин А.В. Туганов фикеренчә, Нигезләмәнең гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар биргән гавами тыңлауларда катнашучы затлар, үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен, чыгыш ясарга хокуклы булуын күз алдында тоткан 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацы кирәгеннән артык булып тора һәм ул гавами тыңлаулар уздыру көнендә гариза бирү мөмкинлеге булу кирәк дип саный.

Шулай ук мөрәҗәгать итүче Нигезләмәнең күрсәтелгән язма гаризаны биргәндә катнашучының паспортын яисә паспортын алыштыручы документын тапшыру турында 7 статьясындагы 4 өлешенең икенче абзацында каралган таләп гражданның аны тапшырганда бары тик үзенең катнашуын күз алдында тота. Моннан тыш, гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гариза биргәндә электрон рәвештә гариза җибәрү мөмкинлеге булмавын күрсәтә.

Гражданин А.В. Туганов фикеренчә, Нигезләмәнең 9 статьясындагы 5 өлешендә беркетелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәнең эчтәлегенә карата таләпләрдән һәм аның Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында китерелгән формасыннан чыгып, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләү булырга тиеш

түгел. Шул ук вакытта, җирле үзидарәне оештыру нигезләрен җайга салучы федераль закон нормалары буенча, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне үз эченә алырга тиеш. Шуның белән ул Нигезләмәнең 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм аңа 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән җирле үзидарә органнары гамәлләренең һәм карарларының законлылыгы принцибына каршы килә дип саный.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары Район башлыгы урынбасары тарафыннан имзалана, ул, мөрәҗәгать итүче раслаганча, мондый вәкаләтләргә ия булмаган. Әлеге карар аның тарафыннан Район башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән сигез ай узгач имзаланган, әмма «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — 131-ФЗ номерлы Федераль закон) 36 статьясындагы 8.1-1 өлеше нигезендә муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң алты айдан да соңга калмыйча яңа башлык сайлана.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлешен, 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлеше, 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләрен, 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләрен, шулай ук тулаем күрсәтелгән карарны Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 3 (икенче өлеш), 10, 22, 24 (икенче өлеш), 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 45 (беренче өлеш) һәм 116 (беренче

һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә, кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; халык үз хакимиятен турыдан-туры, шулай ук дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашыра; Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә; җирле үзидарә үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль; җирле үзидарә органнары дәүләт хакимияте органнары системасына керми; Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары буенча һәм Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә таныла һәм гарантияләнә; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; Татарстан Республикасында гражданнар сәяси тормышта, дәүләт һәм җәмәгать эшләре белән идарә итүдә турыдан-туры да, үз вәкилләре аша да катнашырга хокуклы; җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә; җирле үзидарә референдум, сайлаулар уздыру юлы белән, турыдан-туры ихтыяр белдерүнең башка рәвешләре аша,

җирле үзидарәнең сайланулы һәм башка органнары, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары аша гражданнар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала; бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлеше, гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы 100 кешедән дә ким булмаган гражданнар төркеменнән чыгып эш итә ала дип билгеләгән дәрәҗәдә;

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре,

гавами тыңлаулар үткәрү срогын билгеләү мәсьәләсен җайга салу өлешендә;

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацлары, алар гражданнарның чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуы гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән һәм паспортны яки паспортны алмаштыручы документны күрсәтү шарты белән мөмкин булуын күздә тота;

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләре, үзенең сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып, кабул ителгән карарларны дәлилләп нигезләмичә генә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә кабул итүгә рөхсәт иткән дәрәҗәдә;

— «Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары тулаем алганда, аны имзалау тәртибе буенча.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган нигезләмәләр җирле үзидарәне оештыру өлкәсенә кагыла.

Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларын билгеләү Россия Федерациясенең һәм

Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагына керә (72 статьяның 1 өлешендәге «н» пункты), алар буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителүче законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла (76 статьяның 2 өлеше). Россия Федерациясе Конституциясенең әлеге нигезләмәләре Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, территориаль, оештыру һәм икътисадый принциплары, аны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләре беркетелгән 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба шулай ук — 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) үз үсешен алган.

Югарыда күрсәтелгән Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә җирле үзидарә — ул халыкның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, ә федераль законнарда каралган очракларда — Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән чикләрдә тәэмин ителүче үз хакимиятен, халык мәнфәгатьләреннән чыгып, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык һәм (яисә) җирле үзидарә органнары аша мөстәкыйль рәвештә һәм җаваплылыкны үз өстенә алып гамәлгә ашыру рәвеше (1 статьяның 2 өлеше).

Муниципаль берәмлекләр халкы тарафыннан турыдан-туры һәм (яисә) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, 131-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары конституцияләренә (уставларына), законнарына, башка норматив-хокукый актларына каршы килмәскә тиеш (131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 һәм 4 өлешләре).

Әлеге Федераль законның 28 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гавами тыңлауларны оештыруның һәм уздыруның тәртибе муниципаль берәмлек уставында һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив-хокукый актларында билгеләнә. 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында муниципаль берәмлек уставы белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә халыкның катнашу формалары, тәртибе һәм гарантияләре билгеләнергә тиеш дип каралган.

Китерелгән федераль һәм республика законнары нормалары Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставының, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында гавами тыңлауларны үткәрүне оештыруга карата төп таләпләрне билгеләүче 18 статьясының хокукый нигезен тәшкил иткән. Әлеге статьяның 10 өлеше нигезендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе Район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә, аны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә расланган.

Шулай итеп, карала торган Нигезләмәне кабул итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы үзенә бирелгән вәкаләтләр кысаларында эш иткән.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 статьясындагы беренче өлеше нигезендә җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итә. Шундый ук нигезләмә Россия Федерациясе

Конституциясенең 130 статьясындагы 1 өлешендә дә бар.

Күрсәтелгән конституциячел нормаларга 1985 елның 15 октябрендәге, Россия Федерациясе тарафыннан 1998 елның 11 апрелендә ратификацияләнгән, Европа җирле үзидарә хартиясенең 3 статьясы туры килә, ул җирле үзидарәне җирле үзидарә органнарының закон кысаларында, җаваплылык тоеп һәм җирле халык мәнфәгатьләрендә эш итеп, гавами эшләрнең күп өлешен җайга салу һәм алар белән идарә итү хокукы һәм реаль сәләте дип билгели (1 пункт); тиешле советлар яисә җыелышлар һәм аларга хисап бирергә тиешле башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган бу хокук, законда рөхсәт ителгән очракта, гражданнар җыелышларына, референдумга яки гражданнарның турыдан-туры катнашуының теләсә кайсы башка формасына мөрәҗәгать итүе кире кагылмый (2 пункт).

Җирле үзидарәне халыкның үзенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне мөстәкыйль һәм үз җаваплылыгы астында хәл итүне тәэмин итәргә тиешле территориаль үзоешу буларак аңлау, Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, җирле берләшмә хакимияте буларак, муниципаль хакимиятнең табигатен һәм, халыкка иң якыннары буларак, җирле үзидарә институтларының үзенчәлекләрен исәпкә алуны шарт итеп куя. Турыдан-туры һәм җирле үзидарә органнары аша муниципаль хакимиятне мөстәкыйль гамәлгә ашыру хокукына ия субъект — муниципаль берәмлек халкы (2002 елның 2 апрелендәге 7-П номерлы Карар, 2002 елның 10 апрелендәге 92-О номерлы, 2008 елның 6 мартындагы 214-О-П номерлы билгеләмәләр).

Гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан белдерелгән халык фикерен исәпкә алу гарантияләренең берсе булып тора.

Россия Федерациясе Конституциясенең 3 статьясы һәм гавами тыңлауларны уздыру җайга салына торган федераль законнарның мәгънәсе буенча гавами тыңлаулар халык тарафыннан хакимиятне гамәлгә ашыру формасы булып тормый. Шулай да алар, аны кабул итүгә компетентлы

органнар һәм вазыйфаи затлар хокуклы булган күздә тотылган карар кагылырга мөмкин булган һәркемгә, махсус белемнәре булуга яисә билгеле бер оешмаларга һәм берләшмәләргә карауларына бәйсез рәвештә, аның турында фикер алышуда катнашу мөмкинлеген бирә. Мондый тикшерүнең ахыргы максаты — иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча рекомендацияләр эшләү йә хокукый актка иҗтимагый бәя бирү. Шуңа бәйле рәвештә идарә итү карарларын кабул итү процессы гражданнар өчен ачык була бара һәм бу ачыклык хакимият органнарын билгеле мәсьәләләр буенча гавами тыңлаулар үткәрүне йөкли торган законның мәҗбүри көче белән тәэмин ителә (Россия Федерациясе Конституция Судының 2010 елның 15 июлендәге 931-О-О номерлы билгеләмәсе).

Карала торган нигезләмә буенча гавами тыңлаулар — Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектларын җәмәгать фикер алышу юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында катнашу, шулай ук федераль законнарда, әлеге Нигезләмәдә беркетелгән мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен Район халкының хокукларын гамәлгә ашыру формасы булып тора (1 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты).

3.1. 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә гавами тыңлаулар, шул исәптән халык инициативасы буенча, муниципаль берәмлектә яшәүчеләр катнашында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актларның проектлары хакында фикер алышу өчен уздырыла (1 һәм 2 өлешләр).

Күрсәтелгән Федераль закон, халык инициативасы буенча гавами тыңлаулар уздыру мөмкинлеген билгеләп, инициатив төркем гражданнарының мәҗбүри булган минималь санына карата таләпләр билгеләми, шул рәвешле әлеге мәсьәләне хәл итүне муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләренә калдыра.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы, үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында эш итеп, Нигезләмәнең шикаять

белдерелә торган 4 статьясындагы 2 өлешендә гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы чыгарга мөмкин булган гражданнар төркеменең минималь санын билгеләгән — 100 кеше.

Әлеге хокукый җайга салу, җирле үзидарәнең беренчел субъекты буларак, максаты халыкка закон гарантияләрен тәэмин итү булган сан критерийларын билгеләү кирәклегеннән, җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны, тиешле муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын тикшерүгә, тормыш өчен мөһим булган, шул исәптән муниципаль норматив хокукый актлар кабул итүгә һәм аларга үзгәрешләр кертүгә кагылышлы мөһим мәсьәләләргә карата үз позициясен белдерү мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан чыгып билгеләнә (Нигезләмәнең 2 пунктындагы 1—4 пунктчалары).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, ул аңлатканча, гавами тыңлаулар нәкъ менә күмәк фикерне яисә индивидуаль характерда булмыйча, шулай ук күмәк характердагы фикерләрдә ачык чагылдырылган аермаларны ачыклау максаты белән, тиешле гавами берәмлек территориясендә яшәүче гражданнар өчен мөһим булган иҗтимагый әһәмиятле проблемалар (мәсьәләләр) турында ачык, бәйсез һәм ирекле фикер алышуны тәэмин итүгә юнәлдерелгән гавами-хокукый институт булып тора (2010 елның 15 июлендәге 931-О-О номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 211-О номерлы билгеләмәләре).

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды, гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы чыгарга мөмкин булган гражданнарның минималь санын күздә тоткан Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлеше федераль закон нормаларына нигезләнгән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советына бирелгән вәкаләтләр кысаларында кабул ителгән, коллектив фикерне ачыклау максатына җавап бирә, район халкының гавами тыңлаулар үткәрү инициативасы белән чыгу һәм шул рәвешле җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында катнашу хокукы асылына каршы

төшми, аның эчтәлеген югалтуга китерми, гражданнарның, шул исәптән гражданин А.В. Тугановның да конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗәгә килә.

3.2. 131-ФЗ номерлы Федераль законның (мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдә булган редакциясендә) 28 статьясы нигезендә гавами тыңлауларны оештыруның һәм уздыруның тәртибе гавами тыңлаулар уздыру вакыты һәм урыны турында муниципаль берәмлек халкына алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан таныштыруны, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда катнашуын тәэмин итә торган башка чаралар, кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне дә кертеп, гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка игълан итүне) күздә тотарга тиеш (4 өлеш). Мәгънәсе буенча охшаш нигезләмәләр Уставның 18 статьясында беркетелгән.

Нигезләмәнең эзлекле бәян ителүдә карала торган үзара бәйле нормаларыннан күренгәнчә, гавами тыңлауларны үткәрүнең оештыру-процедура механизмы этаплап түбәндәгеләрдән гыйбарәт: Район Советы карары белән гавами тыңлауларны билгеләү, аннары муниципаль хокукый актны бастырып чыгару юлы белән гавами тыңлауларны билгеләү турында халыкка хәбәр итү, анда шул исәптән гавами тыңлаулар мәсьәләсе (гавами тыңлауларда фикер алышырга тиешле муниципаль хокукый акт проектының исеме һәм тексты), гавами тыңлауларны үткәрү датасы, урыны (адресы) һәм вакыты булырга тиеш, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү, муниципаль хокукый акт проекты буенча күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр җыю, гавами тыңлаулар уздыру һәм ахырда гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару (5 статьяның 1 өлеше, 6 статьяның 2 өлеше, 7 статьяның 2 өлеше, 8 һәм 9 статьялар). Шул ук вакытта гавами тыңлауларга чыгарылган һәр мәсьәлә буенча, шул исәптән Устав проекты һәм Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты буенча, Нигезләмә аларны карау үзенчәлекләрен күздә тота.

Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулар срогы гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт басылып чыккан көннән алып гавами тыңлауларга, җәмәгать фикер алышуларга чыгарылган сорауларга бәйле рәвештә, 30 көннән алып өч айга кадәр булган диапазонда билгеләнгән. Шул ук норманың икенче абзацы нигезендә Устав проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру срогы 30 көннән дә ким түгел.

Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләреннән чыгып, Нигезләмәнең 13 статьясындагы шикаять белдерелә торган 4 өлеше Устав проекты яисә Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар Район Советы тарафыннан билгеләнә һәм Устав тарафыннан билгеләнгән срокларда, ләкин күрсәтелгән проектлар басылып чыкканнан соң, 15 көннән иртәрәк булмаган вакытта уздырылуын күздә тота. Әлеге формулировканы куллану район халкын күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектлары белән гавами тыңлаулар үткәргәнче таныштыруны гарантияләүче минималь срокны билгеләүгә юнәлдерелгән.

Димәк, гражданин А.В. Туганов дәлилләренә карамастан, дәгъва белдерелә торган нормалар бер-берсенә каршы килми, чөнки мәгънәләрендә аерма бар: Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында беркетелгән 30 көнлек срок гавами тыңлаулар билгеләү турында муниципаль хокукый акт басылып чыккан көннән алып аларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр гавами тыңлаулар уздыру процессының бөтен этапларын үз эченә ала, ә Нигезләмәнең 13 статьясындагы 4 өлешендә каралган 15 көнлек срок муниципаль хокукый актларның атап үтелгән проектлары басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр вакыт интервалы булып тора, шуның белән 4 өлешнең гамәлдә булуы Район халкын күрсәтелгән муниципаль хокукый актлар проектлары белән алдан таныштыруны тәэмин итүгә һәм аларга карата күрсәтмәләр һәм

тәкъдимнәр бирү мөмкинлегенә кагыла.

Шулай итеп, Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацындагы һәм 13 статьясындагы 4 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүче хокукларын, юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры киләләр.

3.3. Гавами тыңлауларны оештыру процессы шул исәптән гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәр җыюны үз эченә ала (Нигезләмәнең 7 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктчасы). Шул ук вакытта гавами тыңлауларда катнашучылар фикер алышына торган мәсьәләләргә кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), яшәү (теркәү) урыны адресын күрсәтеп, алдан ук та, гавами тыңлаулар үткәрү көнендә дә тапшырырга хокуклы (Нигезләмәнең 7 статьясындагы 3 өлеше). Нигезләмәнең 7 статьясындагы 5 пункты нигезендә гавами тыңлауларда, гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукыннан башка, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең барлык кызыксынган халкы катнаша ала.

Гражданнарның чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуы гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар биргән һәм паспортын яисә паспортын алыштыручы документын тапшыру шарты белән мөмкин булуын күз алдында тоткан Нигезләмәнең 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацлары гавами тыңлаулар оештыру элементларының берсе булып тора. Үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча алар гавами тыңлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә, шул исәптән тиешле регламент формалаштыруга юнәлтелгән, аның белән, Нигезләмәнең 8 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, карала торган мәсьәләнең эчтәлеген, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен кергән язма гаризаларның санын исәпкә алып, чыгышларның эзлеклелеге һәм вакыты, башка мәсьәләләр

билгеләнә.

Нигезләмәнең 7 статьясындагы 4 өлешенең икенче абзацында каралган паспортын яисә паспортын алыштыручы документын тапшыру турында, мөрәҗәгать итүченең үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гариза биргәндә үзенең булуын күз алдында тоткан таләп, мондый гаризаны биргән затны билгеләү һәм, асылда, гавами тыңлаулар үткәргәндә аның хокукларын яклауга юнәлдерелгән кирәкле шарт булып тора. Аерым алганда, гавами тыңлауларда каралган мәсьәләгә кагылышлы тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр керткән гавами тыңлауларда катнашучы гавами тыңлаулар беркетмәсеннән аның тарафыннан кертелгән тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне үз эченә алган өземтәне алырга хокуклы (Нигезләмәнең 9 статьясындагы 4 өлеше), гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәнең эчтәлегенә карата күрсәтмәләрнең берсе — гавами тыңлауларда катнашучылар турында мәгълүмат күрсәтү (Нигезләмәнең 9 статьясындагы 5 өлешенең 5 пункты).

Күрсәтелгән хокукый җайга салу гавами тыңлаулар үткәрүне оештыру процедурасын тәртипкә салуны тәэмин итү максатларыннан чыга, аларда катнашучы гражданнарның хокукларын яклауга юнәлдерелгән һәм шул рәвешле кеше һәм гражданның, шул исәптән гражданин А.В. Тугановның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Мөрәҗәгать итүченең билгеләнгән документлар пакетын инициатив төркем тарафыннан электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге булмау турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициативасы белән мөрәҗәгать итү хокукы закон белән тәэмин ителгән һәм бары тик мөрәҗәгать итүчеләр гамәлләренә генә бәйле, димәк, документларны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге булмау үзеннән-үзе хокукның асылына каршы төшә торган буларак карала

алмый, чөнки мондый тәртипне кертү вәкаләтле органга (затка) гражданнар төркеменең ихтыяр белдерүенең эчтәлеген җиткерүнең өстәмә ысулы гына булачак.

Күрсәтелгәннәр тулысынча гражданның тәкъдимнәрне аргументацияләү өчен чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү тәртибенә кагылышлы хокукый җайга салуга да керә.

3.4. 131-ФЗ номерлы Федераль законның (мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән вакытка гамәлдә булган редакциясендә) 28 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гавами тыңлауларны оештыруның һәм уздыруның тәртибе муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда катнашуын, кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне дә кертеп, гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны (халыкка игълан итүне) тәэмин итә торган чараларны күздә тотарга тиеш.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, закон чыгаручы, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 4 өлешендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгеләүче һәм мондый актның эчтәлегенә таләпләрне беркетүче муниципаль хокукый актны кабул итүне күздә тотып, җирле үзидарә органнарына гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен билгеләү процедурасын җайга салганда билгеле бер дискреция биргән (2021 елның 26 февралендәге 211-О номерлы билгеләмә).

Китерелгән федераль законнар нигезендә Район Советы Уставның 18 статьясындагы 9, 10 өлешләре нигезләмәләре белән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре мәҗбүри басылып чыгарга тиеш һәм кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне үз эченә алырга тиеш дип беркеткән.

Нигезләмәнең 3 бүлеге гавами тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү тәртибен беркетә, аның 9 статьясында гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгаклау карарларын кабул итү процедурасы җайга салынган. Шулай итеп, Нигезләмәнең шикаять белдерелә торган 9 статьясындагы 5 өлешендә мәҗбүри йомгаклау документы булып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә тора дип билгеләнгән. Шул ук вакытта дәгъва белдерелә торган

норманы Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган 3 нче кушымтасы белән норматив бердәмлектә карарга кирәк, анда гавами тыңлауларны билгеләп кую турында муниципаль хокукый актның датасы, номеры һәм атамасы, шулай ук аны рәсми бастырып чыгару датасы күрсәтелә; каралуга чыгарылган мәсьәлә (сораулар); чараны үткәрү инициаторы; гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны; гавами тыңлауларны үткәрүче оештыру комитеты; гавами тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясау хокукына ия булучылар турында мәгълүмат; гавами тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге мәсьәләне (сорауларны) хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге, ул шул исәптән экспертларның һәм катнашучыларның тәкъдимнәре һәм рекомендацияләре турында мәгълүматны үз эченә ала; җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты; гавами тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре; гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә формасы китерелә.

Әлеге хокукый җайга салу йомгаклау документын кабул иткәндә аңа мотивлаштырылган нигезләү кертү мәҗбүри булуын күз алдында тоткан федераль законнар һәм Уставның китерелгән нормалары белән системалы бердәмлектә кулланылырга тиеш. Моннан аңлашылганча, Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган нормаларында бәяләмәгә мотивлаштырылган нигезләү кертү кирәклегенә турыдан-туры күрсәтмәнең үзеннән-үзе булмавы Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килү буларак карала алмый, чөнки бу таләпне үтәүнең мәҗбүрилеген шик астына куймый һәм шикаять белдерелә торган нигезләмәләрне ирекле хокук куллану мөмкинлеген юкка чыгара.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды Нигезләмәнең гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә эчтәлегенә карата таләпләр билгели торган 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм аңа 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләре җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен чын, тулы һәм дөрес исәпкә алу

мөмкинлеген күздә тоталар, Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар проектларын гавами фикер алышу юлы белән җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул итү процессында катнашу өчен Район халкының гарантияләнгән хокукларын тәэмин итүнең конституциячел әһәмиятле максатларын күздә тоталар, шуңа күрә гражданнарның, шул исәптән гражданин А.В. Тугановның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуга китерә торган буларак карала алмый, һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дигән нәтиҗәгә килә.

Суд утырышында эшне карый башлаган вакытка «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы карары белән карала торган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертелгән, шул исәптән 6 статьяның 3 өлешендә гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулар нәтиҗәләрендә кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләү булуы да күз алдында тотыла.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен рәсмиләштерү процедурасын регламентлаучы нигезләмәләрне бертөрле куллану максатларында гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эчтәлегенә карата таләпләрне төгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү юлы белән хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеге дә кире кагылмый, анда кабул ителгән карарны дәлилләнгән нигезләүгә турыдан-туры күрсәтмә чагыла дип билгели. Мондый үзгәрешләр дәгъва белдерелә торган нормаларның ирекле кулланылышын юкка чыгарыр һәм бу мәсьәләдә мөнәсәбәтләрне җайга салуның билгеләнешенә, ачыклыгына һәм бер мәгънәдә булуына ярдәм итәр иде.

3.5. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның шул исәптән аларны имзалау тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен билгели.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 7 өлеше белән муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта аның вәкаләтләрен үтәү тәртибе билгеләнгән. Шул ук вакытта муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча муниципаль берәмлекнең уставы нигезендә билгеләнүче җирле үзидарәнең вазыйфаи заты яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты башкара. Шундый ук норма 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 9 өлешендә беркетелгән.

Уставның 46 статьясындагы 3 өлеше эчтәлегеннән күренгәнчә, (авыру белән яки ялга бәйле рәвештә) вакытлыча булмаганда яки үз бурычларын үтәү мөмкинлеге булмаганда йә Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта аның вазыйфаларын урынбасары башкара. Яңа сайланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 8.1-1 өлешендә билгеләнгән срокта сайланмавы Район Башлыгы вазыйфаларын аның урынбасары тарафыннан вакытлыча үтәүне туктатуга китермәгән, бу исә үзеннән-үзе Башлык урынбасарының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының әлеге карарын имзалауга вәкаләтләре булмаган дип исәпләргә нигез бирми.

Татарстан Республикасы Конституция суды җирле үзидарә органнары структурасында муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату муниципаль берәмлек белән идарә итү элементының эшләвен тәэмин итү зарурлыгына китерә, аның булуы 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәҗбүри, аларны гамәлгә ашыру турыдан-туры муниципаль

берәмлек халкының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган вәкаләтләрнең законда каралган исемлеген үтәүне күз алдында тотуын игътибарга ала. Бу очракта Уставта муниципаль берәмлек башлыгын сайлау срогы булу муниципаль берәмлек башлыгын алмаштыручы затның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны чикләү вакыты турында түгел, ә яңа муниципаль берәмлек башлыгын сайлауларга йомгак ясаганчы һәм ул үз вазыйфасына керешкәнче аны сайлау процедурасының регламентлаштырылуы йә аның вәкиллекле органы тарафыннан муниципаль берәмлекнең яңа башлыгын сайлау турында сөйли.

Шул ук вакытта муниципаль берәмлекнең яңа башлыгын сайлау датасыннан алдарак тәмамланучы чорны билгеләү юлы белән муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеген чикләү үз асылы буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең кирәкле сәяси-оештыру гарантияләрен, шулай ук муниципаль берәмлекнең иң югары вазыйфаи заты тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә билгеләнә торган җирле үзидарә органнары сәясәтенең тотрыклылыгын һәм бердәмлеген киметә, бу исә муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләренә керүче җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә каршылыклар китереп чыгарырга мөмкин.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары тулаем алганда аны имзалау тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче,

икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны һәм җәмәгать фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 4 статьясындагы 2 өлешен, 6 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацы һәм 13 статьясындагы 4 өлеше, 7 статьясындагы 4 өлешенең беренче һәм икенче абзацларының үзара бәйле нигезләмәләрен, 9 статьясындагы 5 өлешенең һәм әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасының үзара бәйле нигезләмәләрен, шулай ук тулаем күрсәтелгән карарны аны имзалау тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 100-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**